**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Чуаш-Кичүе авыл җирлеге Советы КАРАРЫ**

2015 елның 1 апреле 13№

Чуаш-Кичүе авыл җирлеге территориясендә урнашкан дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен тапшыру турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Әлки муниципаль районының «Чуаш-Кичүе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш-Кичүе авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советына дәүләт милке чикләнмәгән һәм Чуаш-Кичүе авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен кабул итәргә тәкъдим итәргә.
2. Әлки муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Чуаш-Кичүе авыл җирлеге Башкарма комитеты:

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне кушымта итеп бирелгән рәвештә тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш-Кичүе авыл җирлеге Советының 2014 елның 18 декабрендәге «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш-Кичүе авыл җирлеге бюджеты турында»33 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында карары проектын эшләү һәм карауны тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Чуаш-Кичүе авыл җирлегенең мәгълүмат стендында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Чуаш-Кичүе авыл җирлеге башлыгы Н.Р.Закирова